Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2025 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- урамнарны яктырту җайланмасы.

Халык җыенында рәислек итүче Т.В. Савинова

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы Т.В. Савинова